| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ»<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>«БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2020 Баулы шәһәре № 45

Татарстан Республикасының
«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге территориясендә
бердәм җылылык белән тәэмин
итүче оешманы билгеләү турында

Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә өзлексез җылылык белән тәэмин итүне оештыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ Федераль законның 6 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә җылылык белән тәэмин итүне оештыру һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 8 августындагы 808 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Газпром теплоэнерго Казан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятен Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма (алга таба - бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма) итеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясен бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешма эшчәнлеге зонасы итеп билгеләргә.
3. Бердәм җылылык белән тәэмин итүче оешмага капиталь төзелеш объектлары билгеләнгән тәртиптә бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы эшчәнлеге зонасы чикләрендә һәм Татарстан Республикасы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге халкының нормаль яшәешен тәэмин итүче күләмдә үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтырылган абонентларны җылылык белән тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http:bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

«Баулы шәһәре» муниципаль
берәмлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров